ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ МИШӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАР

**(IV чакырылыш)**
Егерме дүртенче утырыш

«21» июль 2023 ел № 87 Олы Мишә ав.

Олы Мишә авыл җирлеге Советының 2013 елның 29 июле 92 номерлы «Алкогольле продукцияне ваклап сату рөхсәт ителмәгән кайбер оешмаларга һәм объектларга якын территорияләрне билгеләү турында» карары үз көчен югалткан дип тану хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм аларның әйләнешен дәүләт җайга салуы турында һәм алкоголь продукциясен куллануны (эчүне) чикләү хакында» 1995 елның 22 ноябрендәге 171-ФЗ номерлы Федераль закон, «Алкоголь продукциясен ваклап сату һәм җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган якын территорияләрнең чикләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләү кагыйдәләрен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 23 декабрендәге 2220 номерлы карары, Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының «Алкогольле продукцияне ваклап сату һәм җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә алкогольле продукцияне ваклап сату рөхсәт ителмәгән кайбер оешмаларга һәм объектларга якын территорияләрнең чикләрен билгеләү турында» 2023 елның 14 июлендәге 108 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Мишә авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Олы Мишә авыл җирлеге Советының 2013 елның 29 июле 92 номерлы «Алкогольле продукцияне ваклап сату рөхсәт ителмәгән кайбер оешмаларга һәм объектларга якын территорияләрне билгеләү турында» карары үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Олы Мишә авыл җирлеге башлыгы: Ф.Б.Җамалетдинов